**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 сентябрь № 701

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү тәртибе хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Законнар нигезендә ТКХ түләүләренә социаль ярдәм чараларына хокуклары булган гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр биргән затлар субсидия-ташламалар алу өчен Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәгенең даими яшәү урыннары буенча бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

субсидия-ташлама бирү турында гаризаны;

законлы вәкилләрнең яки ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр биргән затларның законнар нигезендә ТКХ түләүләренә социаль ярдәм чараларына хокуклары булган гражданнар мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә вәкаләтләрен раслаган документлар күчермәләре.

Законнар нигезендә ТКХ түләүләренә социаль ярдәм чараларына хокуклары булган гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр биргән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклаучы документны, банкта яки бүтән кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын, шулай ук гражданның гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда субсидия-ташламалар алуга хокукын раслаучы документны күрсәтәләр.

Субсидия-ташлама билгеләү һәм алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелә ала. Электрон документлар рәвешендә тапшырылган гаризалар һәм документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларыннан һәм (яки), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырылалар.

Субсидия-ташлама алу өчен кирәкле гаризаны һәм документларны (белешмәләрне) электрон документлар рәвешендә тапшырганда гариза бирүче үзенең шәхси мәгълүматларын компенсация билгеләү өчен кирәк максатларда һәм күләмдә файдалануга рөхсәтен белдерә.».

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\701.docx